Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«10» сентябрь 2019 ел № 128

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 нче февралендәге 106 номерлы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә җирдән файдалану, муниципаль берәмлек төзелешләре кагыйдәләрен раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 27 февраль, 133 нче номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының карары 18 декабрь 2014 ел № 123 белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берлегенең җирдән куллану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 28 статьяның 5 пунктында «Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә.» сүзләрен “әлеге кодекс нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9 өлешләрендә каралган тәртиптә” сүзләре белән алмаштырырга;»;

10 пунктның беренче абзацында:
"техник регламентлар» сүзләрен төшереп калдырырга;
"энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң «(энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь төзелеш объектларыннан тыш)" сүзләрен өстәргә»;

б) 29 статьяның 3 пунктындагы 9 пунктчасында “проект документлары"сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен да кертеп)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы ур., 9;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге”
Советы рәисе А.Г. Җиһаншин